**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2016 ел, 30 декабрь № 1067

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Юридик затларның 2013 – 2017 елларга гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү буенча республика адреслы программасын тормышка ашыру кысаларында төзелгән торак урыннарга милек хокукын дәүләт теркәвенә алуны рәсмиләштерү белән бәйле чыгымнарын каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2016 ел, 22 июль, 500 нче карары белән расланган Юридик затларның 2013 – 2017 елларга гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү буенча республика адреслы программасын тормышка ашыру кысаларында төзелгән торак урыннарга милек хокукын дәүләт теркәвенә алуны рәсмиләштерү белән бәйле чыгымнарын каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Юридик затларның 2013 – 2017 елларга гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү буенча республика адреслы программасын тормышка ашыру кысаларында төзелгән торак урыннарга милек хокукын дәүләт теркәвенә алуны рәсмиләштерү белән бәйле чыгымнарын каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2016 ел, 22 июль, 500 нче карары белән расланган Юридик затларның 2013 – 2017 елларга гражданнарны авария хәлендәге торак

фондыннан күчерү буенча республика адреслы программасын тормышка ашыру кысаларында төзелгән торак урыннарга милек хокукын дәүләт теркәвенә алуны рәсмиләштерү белән бәйле чыгымнарын каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 нче пунктта:

беренче абзацта «түбәндәге» сүзенә кадәр «килешү төзергә планлаштырылган айга кадәр килә торган айның бересенә»;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджетына субсидияләр, бюджет инвестицияләре (шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгән) кайтару буенча вакыты чыккан бурычлары һәм Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджетына бүтән вакыты чыккан бурычлары булмау;

теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы раслый торган салым салуның ташламалы салым режимы күздә тотылган һәм (яки) мондый юридик затларга карата финанс операцияләре үткәргәндә мәгълүмат ачу һәм бирү күздә тотылмаган дәүләтләр һәм территорияләр (офшор зоналар) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган устав капиталларындагы чит ил юридик затлары катнашу өлеше барысы бергә 50 проценттан арткан чит ил юридик затлары, шулай ук Россия юридик затлары булмау;

Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджетыннан башка норматив хокукый актлар нигезендә әлеге Тәртипнең 1 нче пунктында күрсәтелгән максатларга акча алмау.»;

5 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджетыннан башка норматив хокукый актлар нигезендә әлеге Тәртипнең 1 нче пунктында күрсәтелгән максатларга алынган акча, шулай ук Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджетына субсидияләр, бюджет инвестицияләре (шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгән) кайтару буенча вакыты чыккан бурычлары һәм Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджетына бүтән вакыты чыккан бурычлары булмау турында юридик зат җитәкчесе имзалаган гарантия хаты.»;

11 нче пунктта «төзелә» сүзенә кадәр «Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирү турындагы килешүнең Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы билгеләгән бертип формасы нигезендә» сүзләрен өстәргә, «10 көн» сүзләрен «биш көн» сүзләренә алмаштырырга;

12 нче пунктта «14 көн» сүзләрен «биш көн» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2016\1067.doc